**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы**
**Кызылтау авыл җирлеге Советы**

# КАРАР

2020 ел, 17 февраль №177

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Кызылтау авыл җирлегендә Бюджет процессы турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Кызылтау авыл җирлеге Советы **карар итә:**

1.«Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Кызылтау авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 8 ноябрендәге 161 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының Кызылтау авыл җирлегендә бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 9 статьяның 2 пунктындагы сигезенче абзацында "акчаларны исәпкә алу буенча" сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 16 статьяның 6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

6.Җирлекнең муниципаль программалары җирлек бюджеты турындагы карарга үз көченә кергән көннән өч айдан да соңга калмыйча туры китерелергә тиеш»;

в) 23 статьяның 2 пунктындагы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-бюджет һәм акчалата йөкләмәләрне кабул итү һәм исәпкә алу;»;

г) 25 статьяның 3 пунктында "касса" сүзен " казначылык" сүзенә алмаштырырга";

д)27 статьяның 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

7.Җирлек бюджетының үтәлеше турында җирлек Советы карары белән, бюджетның керемнәренең, чыгымнарының һәм дефицитының (профицитының) гомуми күләмен күрсәтеп, хисап финанс елы өчен җирлек бюджетының үтәлеше турында хисап раслана. Җирлек бюджеты үтәлеше турындагы карарга аерым кушымталар белән күрсәткечләр раслана:

бюджет керемнәре классификациясе кодлары буенча;

бюджет чыгымнарының ведомство структурасы буенча чыгымнар;

бюджет чыгымнары классификациясе бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча чыгымнар ;

бюджетлар кытлыкларын финанслау чыганаклары классификациясе кодлары буенча бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары;

2.«а» һәм «г» пунктчалары 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы сайтында җирлек бүлегендә урнаштырырга һәм Кызылтау авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

**Кызылтау авыл җирлеге башлыгы Гаффаров Ш.Р.**